| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>СОВЕТ ШЕМОРДАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>0, Республика Татарстан, Сабинский район,<br>с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2<br>тел. (84362) 3-21-44 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШЭМЭРДЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ<br><br>422050, Татарстан Республикасы, Саба районы,<br>Шәмәрдән авылы, Лермонтов урам, 2 йорт<br>тел. (84362) 3-21-44 |

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ 19.12.2023 КАРАР № 37

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 08.11.2021 ел, № 20 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 12.10.2023 елның 01-54/7098 номерлы тәкъдим ителгән куркыныч индикаторлары турындагы хатын караганнан соң, Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советы Карар итә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел, № 20 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә (алга таба – положение тексты буенча) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаны яна редакциядә Кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shemordan адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәмәрдән выл җирлеге башлыгы А.К.Валиев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге Советының 19.12.2023 елгы 37 нче номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында 2нче Нигезләмә

Муниципаль контроль үткәргәндә контроль чаралар үткәрү өчен нигез буларак кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары

1. Муниципаль торак фондының торак биналары булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсен өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына кертү.

2. Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматларына караганда, контрольдә тотылган зат идарәсендә күп фатирлы йортта гомуми милектәге җитешсезлекләрне бетерү буенча эшләр башкару өчен атнага биштән артык ремонт бригадасы чакырылган очракта.

3. Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган хезмәтләр, күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләр